ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 октябрь 2022 ел № 5773

2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы турында

Россия Федерациясенең Бюджет кодексы, «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ЗРТ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Бер үк вакытта өч һәм аннан да күбрәк бала тууга бәйле рәвештә балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» 2008 елның 20 августындагы УП-397 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында» 1992 елның 28 декабрендәге 708 номерлы карары, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы җирле үзидарә органнарының гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү һәм социаль ярдәм күрсәтү хокукын тормышка ашыру турында» 2009 елның 9 апрелендәге 40/17 номерлы карары, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 июлендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә муниципаль программада каралган чараларны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Халыкны социаль тәэмин итү» 1003 бүлегендә каралган акчалар хисабына 371497,71 мең сум: 2023 ел – 120790,89 мең сум; 2024 ел – 125353,41 мең сум; 2025 ел – 125353,41 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.

3. Башкарма комитетның район хакимиятләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

1) социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – СТБДМС) куллану юлы белән Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм СТБДМС операторы тарафыннан билгеләнгән форматлар нигезендә социаль ярдәм чаралары алучылар турында мәгълүмат җибәрү;

2) социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасын куллану юлы белән Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕГИССО операторы тарафыннан билгеләнгән форматлар нигезендә мәгълүмат алу.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 25 октябрендәге
5773 номерлы карарына
кушымта

## 1 бүлек. 2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы (алга таба – программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокук актының исеме, номеры һәм датасы) | Россия Федерациясенең Бюджет кодексы, «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ЗРТ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Бер үк вакытта өч һәм аннан да күбрәк бала тууга бәйле рәвештә балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» 2008 елның 20 августындагы УП-397 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында» 1992 елның 28 декабрендәге 708 номерлы карары |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе |
| Программаны башкаручылар | Башкарма комитетның район хакимиятләре<br>Башкарма комитетның мәгариф идарәсе<br>Башкарма комитетның мәдәният идарәсе<br>Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе<br>«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе,<br>Башкарма комитетның торак-коммуналь хуҗалык һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе |
| Программаның максаты | Халыкның аерым категорияләренә: пенсионерларга, инвалидларга, балалары булган аз керемле гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү, гаиләнең социаль статусын күтәрү |

<table>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td colspan="5">1. Халыкның аз керемле категорияләренә яки катлаулы тормыш хәлендә калган затларга материаль ярдәм күрсәтү.<br>2. Хәрби бәрелешләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, инвалидлар, инвалид балалар, өлкән буын кешеләре өчен бәйрәм һәм истәлекле даталарга багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү.<br>3. Инвалидларга бәйсез тормыш өчен шартлар булдыру, аларны җәмгыятькә интеграцияләү.<br>4. Халыкның социаль проблемаларны мөстәкыйль чишү мөмкинлекләренә ия булмаган социаль зәгыйфь категорияләрен мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк яклауны тәэмин итү. Өлкән яшьтәге гражданнарның җәмгыять тормышында актив катнашуына булышлык итү.<br>5. Шәһәр ветераннарына, пенсионерларга сәламәтләндерү хезмәтләре курсәтү.<br>6. Балигъ булмаган өч һәм аннан да күбрәк балалары, инвалид балалары булган гаиләләргә ярдәм күрсәтү.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="5">Программа 2023 – 2025 елларда тормышка ашырыла.<br>Муниципаль программаның этаплары аерып күрсәтелми.</td></tr>
<tr><td rowspan="6">Программаны финанслауның күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2023 ел (мең сум)</td><td>2024 ел (мең сум)</td><td>2025 ел (мең сум)</td><td>Тормышка ашыру чорына барлыгы (мең сум)</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>120790,89</td><td>120790,89</td><td>120790,89</td><td>371497,71</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td colspan="5">Халыкның социаль зәгыйфь категорияләрен һәм аз керемлеләрне нәтиҗәле адреслы социаль яклау, авыр тормыш хәлендә калган инвалидларга, халыкның аз керемле категорияләренә төрле юнәлештәге ярдәм күрсәтүнең дәрәҗәсен яхшырту</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруга контрольлек итүне оештыру системасы</td><td colspan="5">Программаның үтәлешенә Башкарма комитетның мәгариф идарәсе контрольлек итә</td></tr>
</table>

## 2 бүлек. Программаны тормышка ашыру өлкәсенең характеристикасы, проблемаларның тасвирламасы һәм аның үсеш прогнозы

Хәзерге вакытта Яр Чаллы шәһәрендә социаль киеренкелекне йомшартуга, халыкның социаль якланмаган категорияләренең иң кискен проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән социаль ярдәм күрсәтү системасының үсүе тенденциясе күзәтелә. Социаль

сәясәтнең стратегик максатларыннан берсе булып социаль ярдәм күрсәтүнең адреслылыгын көчәйтү, ресурсларны гаиләгә, өлкән буынга, инвалидларга ярдәм итүгә туплау кала. Башкарма комитет социаль ярдәм чаралары белән халык тормышының барлык өлкәләрен дә колачларга тырыша.

Яр Чаллы шәһәре территориясендә халыкның аз керемле категорияләренең тормыш сыйфатын яхшырту, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтүне көчәйтү, пенсионерларның, аз керемле балалы гаиләләрнең социаль проблемаларны хәл итү, гаиләнең социаль статусын күтәрү кебек юнәлешләрне тормышка ашыру кабул ителә торган муниципаль программалар нигезендә тормышка ашырыла.

Яр Чаллы шәһәрендә яшәүчеләрнең гомуми санының 25% ка якынын пенсионерлар тәшкил итә. Ялгыз яшәүче өлкәннәрнең саны даими рәвештә арта бара.

Өлкән буынның проблемалары күпкырлы: түбән социаль статус, яшәү рәвешенең кысалары тараю, сәламәтлек торышы, тормышның соңгы чорында үз мөстәкыйльлеген сакларга ирек бирми торган проблемалар. Югарыда санап үтелгән проблемалар өлкәннәрнең төрле социаль ярдәм һәм социаль хезмәт күрсәтүгә ихтыяҗлары артуга китерә.

Яр Чаллы шәһәрендә инвалидлар саны ел саен арта бара. Хезмәт яшендәге инвалидлар һәм инвалид балалар саны саклана, иң мөһим бурычларның берсе-мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне җәмгыятькә интеграцияләү проблемасын, шул исәптән программа чаралары белән дә хәл итәргә мөмкинлек бирүче комплекслы күп профильле реабилитация системасын формалаштыру.

Безнең шәһәр территориясендә аз керемле, балигъ булмаган балалары булган гаиләләргә, балигъ булмаган балалары булган тулы түгел гаиләләргә, күп балалы гаиләләргә, имин булмаган гаиләләргә, авыр тормыш хәлендә (социаль куркыныч шартларда) калган гаиләләргә, девиант тотышлы балигъ булмаган балаларга ярдәм итү мәсьәләләре дә актуаль булып кала. Барлык бу категория гаиләләр һәм балалар төрле хезмәтләр күрсәтүгә һәм ярдәмгә мохтаҗ.

Коммуналь хезмәтләргә, азык-төлеккә, кием-салымга, мәктәп кирәк-яракларына бәяләрнең артуы, гаиләләрнең торак белән аз тәэмин ителүе белән беррәттән, балигъ булмаган балалары булган гаиләләрнең җан башына уртача керемнең халыкның башка төркемнәре белән чагыштырганда элеккечә түбән булуына китерә. Инвалид балалары булган гаиләләр гомуми белем алу һәм балаларны тормыш шартларына җайлаштыру мәсьәләсендә аерым игътибар таләп итә.

Шәһәр территориясендәге социаль-демографик ситуациядә халык арасында ана һәм бала институтының әһәмияте арта. 3 балалы гаиләләрнең саны арту тенденциясе күзәтелә, бу – балалары булган гаиләләрнең тормыш шартларын һәм сыйфатын яхшырту буенча чаралар комплексын үз эченә алган социаль яклауның адекват системасын булдыру кирәклеген аңлата.

## 3 бүлек. Программаның төп максатлары һәм бурычлары, тормышка ашыру сроклары һәм этаплары

Максат – халыкның аерым категорияләренә: пенсионерларга, инвалидларга, балалары булган аз керемле гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү, гаиләнең социаль статусын күтәрү.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү куздә тотыла:

1. Халыкның аз керемле категорияләренә яки катлаулы тормыш хәлендә калган затларга материаль ярдәм күрсәтү.

2. Хәрби бәрелешләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, инвалидлар, инвалид балалар, өлкән буын кешеләре өчен бәйрәм һәм истәлекле даталарга багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү

3. Инвалидларга бәйсез тормыш өчен шартлар булдыру, аларны җәмгыятькә интеграцияләү.

4. Халыкның социаль проблемаларны мөстәкыйль чишү мөмкинлекләренә ия булмаган социаль зәгыйфь категорияләрен мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк яклауны тәэмин итү. Өлкән яшьтәге гражданнарның җәмгыять тормышында актив катнашуына булышлык итү.

5. Ветераннарга, пенсионерларга сәламәтләндерү хезмәтләре курсәтү.

6. Балигъ булмаган өч һәм аннан да күбрәк балалары, инвалид балалары булган гаиләләргә ярдәм күрсәтү.

Программа 2023 – 2025 елларда тормышка ашырыла.

Программаның этаплары аерып күрсәтелми.

## 4 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2023-2025 елларга Программаны финанслау күләме 371497,71 мең сум тәшкил итә.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

Барлык чорга 371497,71 мең сум, шул исәптән Программаны тормышка ашыру еллары буенча:

2023 елга –120790,89 мең сум,

2024 елга –125353,41 мең сум,

2025 елга –125353,41 мең сум.

## 5 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

Яр Чаллы шәһәре халкын адреслы социаль яклау Программасын тормышка ашыруның нәтиҗәсе түбәндәгеләр: халыкның социаль проблемаларны мөстәкыйль чишү мөмкинлекләренә ия булмаган социаль зәгыйфь категорияләрен мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк яклауны тәэмин итү, аларны социаль яклау буенча чаралар үткәреп җәмәгать тормышына ныграк тарту, өлкән яшьтәге гражданнарның җәмгыять тормышында актив катнашуы.

Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү Программаны тормышка ашыруның барлык срогы дәвамында ел саен үткәрелә.

6 бүлек. Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләүнең индикаторлары һәм программаны чаралар буенча финанслау

| № т/б | Чараның исеме | Башкаручылар | Үтәү сроклары (ел саен) | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2022 (база) | 2023 кеше | 2024 кеше | 2025 кеше | 2023 (мең сум) | 2024 (мең сум) | 2025 (мең сум) |
| | | | | | | | | | муниципаль бюджет | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Максатның исеме: халыкның аерым категорияләренә: пенсионерларга, инвалидларга, балалары булган аз керемле гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү, гаиләнең социаль статусын күтәрү | | | | | | | | | | | |
| 1 бурыч. Халыкның аз керемле категорияләренә яки катлаулы тормыш хәлендә калган затларга материаль ярдәм күрсәтү | | | | | | | | | | | |
| 1. | Халыкның аз керемле категорияләренә яки 1) катлаулы тормыш хәлендә калган; 2) туганлык мөнәсәбәтләрендә булган кешесенең янгын вакытында вазыйфаи бурычларын үтәгәндә яки башка шундый сәбәп белән үлүе аркасында авыр тормыш хәлендә калган затларга материаль ярдәм күрсәтү: | Башкарма комитетның район хакимиятләре | Ел дәвамында | кеше саны | 4 | 10 | 10 | 10 | 100,00 | 100,00 | 100,00 |
| | барлыгы: | | | | | | | | 100,00 | 100,00 | 100,00 |
| 2 бурыч. Хәрби бәрелешләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, инвалидлар, инвалид балалар, өлкән буын кешеләре өчен бәйрәм һәм истәлекле даталарга багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү | | | | | | | | | | | |
| 2. | Әфганстандагы хәрби бәрелешләрдә катнашучы-инвалидларны, һәлак булганнарның гаилә әгъзаларын бүләкләү (15 февраль – Әфганстан Республикасыннан гаскәрләрне чыгару көне) | Башкарма комитетның район хакимиятләре | 15 февраль | кеше саны | 112 | 112 | 112 | 112 | 112,00 | 112,0 0 | 112,0 0 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Сәләтле балалары булган күп балалы аналарн 8 март – Халыкара хатын-кызлар көне белән котлау | «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе, | 8 март | кеше саны | 30 | 30 | 30 | 30 | 40,00 | 40,00 | 40,00 |
| 4. | Шәһәр ветераннар һәм пенсионерлар Советы активистлары өчен чаралар үткәрү | Автозавод районы хакимияте | | кеше саны | 0 | 30 | 30 | 30 | 38,00 | 38,00 | 38,00 |
| 5. | Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм ветераннарга 9 май-Җиңү көненә истәлекле бүләкләр | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте | 1 – 10 май | кеше саны | 60 | 60 | 60 | 60 | 150,00 | 150,00 | 150,00 |
| 6. | Өлкәннәр көненә багышланган тантаналы чара үткәрү | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте | 1 октябрь | кеше саны | 158 | 100 | 100 | 100 | 150,00 | 150,00 | 150,00 |
| 7. | Сәләтле балалары булган һәм производствода уңышлы эшләүче күп балалы аналарны бүләкләү (27 ноябрь – Әниләр көне) | «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе | 27 ноябрь | кеше саны | 25 | 25 | 25 | 25 | 60,00 | 60,00 | 60,00 |
| 8. | Сәләтле балалары булган һәм производствода уңышлы эшләүче күп балалы аналарны бүләкләү | Башкарма комитетның | 27 ноябрь | кеше саны | 75 | 75 | 75 | 75 | 90,00 | 90,00 | 90,00 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | (27 ноябрь – Әниләр көне) | район хакимиятләре | | | | | | | | | |
| 9. | Ватан Геройлары көненә багышланган тантаналы чаралар үткәрү | Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте | 9 декабрь | кеше саны | 4 | 10 | 10 | 10 | 40,00 | 40,00 | 40,00 |
| 10. | Татарстан Республикасы һәм Яр Чаллы шәһәре үсешенә зур өлеш керткән Мактаулы гражданнарны, гражданнарны җирләү чаралары | Башкарма комитетның район хакимиятләре | ел дәвамында | кеше саны | 1 | 2 | 2 | 2 | 20,00 | 20,00 | 20,00 |
| 11. | «Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы» исеме бирелгән затларга айлык акчалар түләү | Шәһәр Башкарма комитеты | ел дәвамында | кеше саны | 111 | 111 | 111 | 111 | 1533,06 | 1533,06 | 1533,06 |
| 12. | БВС ветераннарын, хәрби бәрелешләр ветераннарын, тәзүче-ветераннарны календарь бәйрәмнәр белән (23 февраль, 8 Март, 9 Май)котлау, шәһәр һәм республика үсешенә зур өлеш керткән юбилярларны (90,95,100 яшь һәм өлкәнрәк) котлау | Башкарма комитет | ел дәвамында | кеше саны | 0 | 300 | 300 | 300 | 565,97 | 565,97 | 565,97 |
| 13. | Ишек алды спорт төрләре фестивален оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте | октябрь | кеше саны | 300 | 350 | 400 | 400 | 50,00 | 50,00 | 50,00 |
| | барлыгы: | | | | | | | | 2849,03 | 2849,03 | 2849,03 |
| 3 бурыч. Инвалидларга бәйсез тормыш өчен шартлар булдыру, аларны җәмгыятькә интеграцияләү | | | | | | | | | | | |
| 14. | Саңгыраулар җәмгыяте активистларын 26 сентябрь - Бөтендөнья саңгыраулар көнендә бүләкләү | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте | 26 сентябрь | кеше саны | 20 | 20 | 20 | 20 | 20,00 | 20,00 | 20,00 |
| 15. | Сукырлар җәмгыяте активистларын 13 ноябрь - Бөтендөнья сукырлар көнендә бүләкләү | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте | 13 ноябрь | кеше саны | 20 | 20 | 20 | 20 | 20,00 | 20,00 | 20,00 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 16. | Шәһәр «Инвалидлар Сабантуе»н үткәрү | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте | июнь | кеше саны | 2 000 | 2 000 | 2 000 | 2 000 | 280,00 | 280,00 | 280,00 |
| 17. | Инвалидларны, инвалид балаларны физик культура һәм спорт аша социаль-мәдәни тернәкләндерү буенча Халыкара инвалидлар көне һәм Инвалидлар ункөнлегенә багышланган чаралар үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел дәвамында | кеше саны | 1000 | 1000 | 1000 | 1000 | 187,00 | 187,00 | 187,00 |
| 18. | Инвалидларны, инвалид балаларны физик культура һәм спорт аша социаль-мәдәни тернәкләндерү буенча Халыкара инвалидлар көне һәм Инвалидлар ункөнлегенә багышланган чаралар үткәрү | Башкарма комитетның район хакимиятләре | декабрь | кеше саны | 320 | 600 | 600 | 600 | 433,00 | 433,00 | 433,00 |
| 19. | Инвалидларны, инвалид балаларны сәнгать иҗаты аша җәмгыятькә социаль җайлаштыру чаралары үткәрү:<br>инвалид балаларның сәнгать иҗаты шәһәр фестиваленең район турлары;<br>2) инвалид балаларның сәнгать иҗаты шәһәр фестиваленең Гала – концерты | Башкарма комитетның район хакимиятләре | декабрь | кеше саны | 450 | 450 | 450 | 450 | 90,00 | 90,00 | 90,00 |
| 20. | Инвалидларны, инвалид балаларны сәнгать иҗаты аша җәмгыятькә социаль җайлаштыру чаралары үткәрү:<br>инвалид балаларның сәнгать иҗаты шәһәр фестиваленең Гала – концерты | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | декабрь | кеше саны | 450 | 750 | 750 | 750 | 100,00 | 100,00 | 100,00 |
| 21. | Инвалидларның ЮУЙ укулары өчен өлешчә түләү | Башкарма комитетның район хакимиятләре | ел дәвамында | кеше саны | 30 | 4 | 4 | 4 | 13,00 | 13,00 | 13,00 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 22. | Иҗтимагый оешмалар активистларына материаль кызыксындыру чаралары бирү:<br>- ветераннар Советы;<br>- инвалидлар җәмгыяте;<br>- сукырлар җәмгыяте;<br>-саңгыраулар җәмгыяте;<br>- репрессиягә дучар булучылар җәмгыяте | Башкарма комитетның район хакимиятләре | ел дәвамында | кеше саны | 27 | 27 | 27 | 27 | 724,20 | 724,20 | 724,20 |
| | барлыгы: | | | | | | | | 1867,20 | 1867,20 | 1867,20 |
| 4 бурыч. Халыкның социаль проблемаларны мөстәкыйль чишү мөмкинлекләренә ия булмаган социаль зәгыйфь категорияләрен мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк яклауны тәэмин итү. Өлкән яшьтәге гражданнарның җәмгыять тормышында актив катнашуына булышлык итү. | | | | | | | | | | | |
| 23. | Күп балалы, аз керемле, аеруча мохтаҗ гаиләләргә, балигъ булмаган балалары булган авыр тормыш хәлендә калган гаиләләргә мәктәпкә әзерләнгәндә материаль ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның район хакимиятләре. | июль, август, сентябрь | гаиләләр саны | 750 | 900 | 900 | 900 | 1 000,00 | 1 000,00 | 1 000,00 |
| 24. | Инвалид балаларга, аз керемле гаиләләрдәге балаларга яңа ел чаралары үткәрү | Башкарма комитетның район хакимиятләре Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | декабрь | балалар саны | 1 500 | 1700 | 1700 | 1700 | 400,00 | 400,00 | 400,00 |
| 25. | Бер үк вакытта өч бала тапкан аналарга материаль ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның район хакимиятләре | ел дәвамында | кеше саны | 2 | 2 | 2 | 2 | 50,00 | 50,00 | 50,00 |
| | барлыгы: | | | | | | | | 1450,00 | 1450,00 | 1450,00 |
| 5 бурыч. Ветераннарга, пенсионерларга сәламәтләндерү хезмәтләре курсәтү | | | | | | | | | | | |
| 26. | Ташламалы йөрү хокукыннан файдаланучы гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек яки дача коммерцияле булмаган берләшмәләренә пассажирлар йөртүне оештыру | Башкарма комитетның торак-коммуналь хуҗалык һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | ел дәвамында | Пассажирлар йөртү саны | 11 311 | 11 311 | 11 311 | 11 311 | 15 000,0 | 15 000,0 | 15 000,0 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 27. | Мунча хезмәтләре күрсәтү | Башкарма комитетның торак-коммуналь хуҗалык һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | ел дәвамында | Хезмәт күрсәтү саны | 54 442 | 54 442 | 54 442 | 54 442 | 3 000,0 | 3 000,0 | 3 000,0 |
| | барлыгы: | | | | | | | | 18000 | 18000 | 18000 |
| 5 бурыч. Балигъ булмаган өч һәм аннан да күбрәк балалары, инвалид балалары булган гаиләләргә ярдәм күрсәтү. | | | | | | | | | | | |
| 28. | Инвалид балаларны, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларны, муниципаль белем бирү оешмаларында укучы 3 һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итү | Башкарма комитет | ел дәвамында | балалар саны | 6404 | 7300 | 7300 | 7300 | 36010,36 | 37450,78 | 37450,78 |
| 29. | Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның туклануын тәэмин итү | Башкарма комитет | ел дәвамында | балалар саны | - | 35180 | 35180 | 35180 | 60514,3 | 63636,4 | 63636,4 |
| | барлыгы: | | | | | | | | 96524,66 | 101087,18 | 101087,18 |
| | барлыгы: | | | | 79606 | 116921 | 116971 | 116971 | 120790,89 | 125353,41 | 125353,41 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева